Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы "Кызылъяр балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Танып – белү проекты

# «Тылсымлы буяулар илендә»

((икенче кечкенәләр төркеме)

«Кызылъяр балалар бакчасы» тәрбиячесе
Нурутдинова Г.Р.
2017 год

## Педагогик проектның паспорты

- Тулы исеме: «Тылсымлы буяулар илендә».
- Проектта катнашучылар: икенче кечкенәләр төркеме балалары, аларның ата-аналары, тәрбияче.
- Максаты: Буяулар белән эшләүнең төрле методларын практикага кертү; балаларның иҗади-сәнгать мөмкинлекләрен үстерү.
- Бурычлары:
- 1. Балаларда иҗади эшчәнлек белән кызыксыну уяту.
- 2. Балаларны буяулар ярдәмендә төрле экспериментлар ясау белән таныштыру.
- 3. Балаларны традицион булмаган рәсем ясау ысуллары белән таныштыру.
- 4. Ата-аналарга балаларның сәләтләрен үстерү өчен нинди алымнар кулланып булуын күрсәтеп бирү.
- Проектны тормышка ашыру вакыты: 3 ай (16 гыйнвардан 14 апрельга кадәр)
- Проектның төре. Танып белү- иҗадый.
- Нәтиҗәсе. Балаларны рәсем сәнгате белән кызыксындыру.

# Проектның эчтәлеге.

## 1) Кереш өлеш.

- **1.1. Актуальлеге.**
- Һәр бала үзенчә сәләтле. Ләкин баланың сәләте кечкенә орлык кебек. Әлеге орлыктан көчле һәм матур чәчәк үсеп чыксын өчен күп көч куярга кирәк. Безнең тынгысыз вакытта күп кенә ата-аналарның үз балаларының сәләтләрен күрү һәм үстерү өстендә эшләр өчен түземлелекләре дә, вакытлары да җитеп бетмәскә мөмкин. Шуңа зур җаваплылык без – тәрбиячеләр өстенә төшә. Әлеге проект ярдәмендә минем балаларны буяулар иленең тылсымы белән таныштырасым, рәсем сәнгатенә мәхәббәт тәрбиялисем, аларның сәләтләрен ачасым һәм үстерәсем килде.
- **1.2 Проблема.** Балаларның традицион булмаган рәсем ясау ысуллары белән таныш булмаулары һәм буяуларны катнаштырып яңа төсләр табу юлларын белмәүләре.
- **1.3 Працтның гипотезасы.** Әгәр проект барышында без рәсем ясауның кызыклы һәм мавыктыргыч шөгыль булуын күрсәтә алсак, бу балаларда рәсем сәнгатенә мәхәббәт уятыр, аларның сәләтләрен ачарга ярдәм итәр.
- **1.4 Проектны чынга ашыру шартлары.**
- 1) Балаларны сынлы сәнгать әсәрләре белән таныштыру.
- 2) Табигатьнең төсләре һәм матурлыгын күзәтү.
- 3) Дидактик уеннар куллану.
- 4) Әлеге эшкә гаиләне дә тарту.

**1.5 Проекттан көтелгән нәтиҗәләр.**

Прект барышында түбәндәге нәтиҗәләргә ирешербез дип уйлыйбыз:

1) Балаларда традицион булмаган рәсем ясау ысуллары турында күзаллау туар.
2) Балалар әлеге ысулларны үзлектән кулланырга өйрәнерләр.
3) Балаларда рәсем сәнгате белән кызыксыну уяныр.
4) Балаларның кул моторикасы үсәр.
5) Балалар төсләрне яхшы аерырга өйрәнерләр.
6) Ата-аналарның рәсем ясау ысуллары буенча белемнәре артыр, алар балалар белән шөгыльләнергә кирәклекне төшенерләр.

# 7) План

**1. Танып белү үсеше буенча.**

## 1) 1.1 “Табигать төсләре” темасы буенча картиналар карау.

**Максаты: Балаларны табигатьтәге төсләр байлыгы белән таныштыру, аның матурлыгын күрә белергә өйрәтү.**

# 1.2 Эксперименталь эшчәнлек

**Экспериментларның атамалары:** «Төсләрне катыштырабыз”, “Яңа төсләр ясыйбыз”, “Шешәдәге дулкыннар”, “Сөттәге рәсем”.

**Максаты:** Балаларны буяуларны үзара катнаштырып яңа төсләр табарга өйрәтү; буяуларның суда эрүен, май һәм сөтнең буяулар белән катышкач нинди формага керүен күрсәтү.








# Сөйләм үсеше буенча эш

1) **Әкиятләр уку.**

В.Сутеев “Әтәч һәм буяулар”, “Тычкан баласы һәм карандаш”;
И.Полякова “Кызыл буяу хакында әкият”;
Н.Горяев “Яшәгән ди булган ди ике төс – Кара һәм Ак”.

**Максаты:** Балаларны буяулар хакындагы әкиятләр белән таныштыру; аларда матур әдәбият белән кызыксыну уяту.

2) **Буяулар хакындагы табышмаклар белән таныштыру.**

Максаты: Балаларны табышмакларны игътибар белән тыңларга һәм эчтәлеген аңларга өйрәтү.

# Сәнгати -эстетик үсеш

1. **Рәсем ясау.**

1) “Алмалар һәм җимешләр”


Максаты: Түгәрәк формадагы штамп белән кулланып рәсем ясарга өйрәтү.

2) “Чуар эшләпәле гөмбә”, “Диңгез асты патшалыгы”

Максаты: Традицион булмаган ысулларның берсе – бармак белән рәсем ясау техникасы белән таныштыру.


3)”Тылсымлы чәчәк”, “Керпекәй”, “Кояшкай” – учлар ярдәмендә рәсем ясау ысулы белән таныштыру.












4) “Чебиләр”, “Песекәй” – каты кыллы пумала белән төрткеләр ясап рәсем төшерү ысулы белән таныштыру.
5) “Чебиләргә җим”, “Кына гөле”.,“Алъяпкычым бизәкле” – мамыклы таякчыклар ярдәмендә рәсем ясау ысулы белән таныштыру.
6) “Тузганак” – поролон ярдәмендә рәсем ясау ысулы белән таныштыру.
7) “Кичке офык” – юеш кәгазьгә рәсем төшерү ысулы белән таныштыру.
8) “Юллар-юллар” – уенчык машиналарның тәгәрмәчләренә буяу сөртеп, рәсем төшерү ысулы белән таныштыру.











## Социаль – коммуникатив үсеш.

1) “Әтәч һәм буяулар” мультфильмын карау.

Максаты: балаларның кәефләрен күтәрү, төсләрне аера белүләрен ныгыту.

2) Дидактик уеннар: “Нинди төс югалды”, “Бу предмет нинди төстә?”, “Гирлянданы җый”, “Төрле төстәге кер юу машиналары”, “Куяннарны киендер”, “Тычканнарны качыр”.

Максаты: балаларның төсләрне аера белүләрен ныгыту.

## Физик үсеш.

Хәрәкәтле дидактик уеннар: “Төсе буенча үз өеңне тап”, “Төрле төстәге машиналар”, “Төрле төстәге флаглар”

Максаты: балаларның игътибарлыкларын үстерү; төрле якка йөгерү күнекмәләрен ныгыту; төсләрне аерырга өйрәтүне дәвам итү.

## Ата- аналар белән эш.

1) Консультация :“Балаларга иҗат итү өчен шартлар булдырыйк”.
2) “Төсләр иленә сәяхәт” темасы буенча ата-аналар җыелышы.

# Йомгаклау өлеше




1) Ата-аналар һәм балаларның бергәләп ясаган рәсемнәре күргәзмәсе.

Темасы: “Туган ягым төсләре”

Максаты: Рәсем сәнгатенә кызыксыну уяту; ата-аналарда балалар белән бергәләп иҗат итү теләге булдыру; балаларда үз эшләре белән горурлану хисе тәрбияләү; туган ягыбызның матурлыгын күрә белергә өйрәтү.

# Проект эшенең нәтиҗәсе

Проект нәтиҗәле үтте дип әйтергә була. Балалар да, ата -аналар да зур кызыксыну белән катнаштылар. Алда көтелгән нәтиҗәләргә ирештек дип уйлыйм. Әлбәттә, әлеге тема буенча эшне алга таба да дәвам итәрбез традицион булмаган рәсем ысулларын кулланырбыз.